**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 14 июнендәге 2494 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына М-1, 2, 3, 4, 4А микрорайоннары чикләрендә үзгәрешләр кертү турында**

«ИнтегСтрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гаризасы нигезендә, территорияне шәһәр төзелеше документациясе белән тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 апрелендәге 1499 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы карарлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 31 октябрендәге 3710 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына М-1, 2, 3, 4, 4А микрорайоннары чикләрендә, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслау юлы белән, үзгәрешләр кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә кушымтадан (хезмәттә файдалану өчен материаллар) тыш (кушымта), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталына (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
14 июнендәге 2494
номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 4 апрелендәге 2103 номерлы карары белән расланган «Седьмое небо» торак районы территориясен планлаштыру проектына М-1, 2, 3, 4, 4А микрорайоннары чикләрендә кертелә торган үзгәрешләр**

Кушымтага туры китереп, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегендә 1-16 нокталарын алмаштырырга.

______________